Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

# КАРАР

5 февраль 2021 ел № 6/11

Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләрне өзү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районына керүче «Алешкин-Саплык авыл җирлеге», «Зур Аксу авыл җирлеге», «Зур Чынлы авыл җирлеге», «Городище авыл җирлеге», «Звезда авыл җирлеге», «Кече Чынлы авыл җирлеге», «Марс авыл җирлеге», «Матак авыл җирлеге», «Түбән Чәке авыл җирлеге», «Яңа Борындык авыл җирлеге», «Яңа Әлмәле авыл җирлеге», «Яңа Ишле авыл җирлеге», «Үби авыл җирлеге», «Иске Чүпрәле авыл җирлеге», «Иске Кәкерле авыл җирлеге», «Иске Чокалы авыл җирлеге», «Иске Шәйморза авыл җирлеге» «Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлеге», «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре Советлары белән, әлеге җирлекләр Советларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турында төзелгән килешүләрне өзәргә:

җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.Е. Ярухинга йөкләргә.

Глава Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан, Председатель
Совета Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан: М.Р. Гафаров